КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 сентябрь г.Казань № 842

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе турында» 2015 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 апрель, 235 нче; 2016 ел, 13 май, 302 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 972 нче; 2017 ел, 4 октябрь, 757 нче; 2018 ел, 9 апрель, 217 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 788 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр,

белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан Б.И.Исмәгыйлевны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары Радик Расыйх улы Гыйсмәтовны;

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Наил Ринат улы Залаковны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин